**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

**2019 ел, 14 февраль №204**

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында" 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2011 елның 24 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 6 статьяның 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5 пунктчага өстәргә:

«5) әлеге статьяның 3 пунктында каралган нигезләр булу.»;

б)3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Контроль-хисап палатасы Рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары вазыйфаларын биләүче гражданнар Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башлыгы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясендә суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыкта яисә үзлектә (ата-аналар, хатынының яки ире, балалары, бертуганнары, шулай ук хатыны яки иренең бертуганнары, ата-аналары, хатыны яки иренең балалары, балаларының ире яки хатын) була алмыйлар.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башлыгы урынбасары Л.Т. Хантимировка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль район Советы рәисе, Р.Н. Заһидуллин**
**Татарстан Республикасы Апас муниципаль район Башлыгы**